

3700 кеше яши торган Рузаевка рай-оны Татар Пешләсе авылында «Татар йорты» милли мәдәният музее 20 мартта ачылды. Ул жирле Мәдәният йорты фой-есында урнашкан.

Музейнын топ идеясе - иске әйберләр белән бvлмәне торгызу гына тvгел, ә нәкъ менә милли йорт атмосферасын кvрсәтv. Милли мәдәният музеенда бvгенге конгә кадәр булган гореф-гадәтләр һәм йола-лар белән танышырга момкин.

Музей киштәләрендә авылдашлары алып килгән борынгы раритетлар: му-зыкаль инструментлар, баш киемнәре коллекцияләре (милли тvбәтәйләр, шәлләр һәм калфаклар), кулдан эшләнгән итекләр, чуен утюглары, ке-росин лампалары, самаварлар, чынаяк-лар жыелмалары һәм башка экспонат-лар бар. Шулай ук музейда бар кешегә дә билгеле булган бишек, борынгы мич урнашкан. Элек-электән мич жылыта, ашата, яктырта, юа, киптерә, дәвалый. Мичләр, гадәттәгечә, зур иттереп чы-гарылган; алар тирәсендә топ йорт эшчәнлеге һәм гаилә ялы булган. Мич янында милли ризыклар белән остәл бар, анда йорт хужалары утыра. Алар Татар Пешләсенен мәдәниятен ачык кvрсәтә. Кvп кенә предметлар кулдан ясалган һәм аларнын һәркайсы vз тарихына ия. Музей кунаклар һәм турист-лар очен ачык. Хәзер «Татар йорты» милли мәдәниятнен искит-кеч музее жирле ха-лыкны һәм туристлар-ны соендерә. Биредә авыл халкынын мил-ли колориты, татар халкынын гореф-га-дәтләре белән таны-шырга, мастер-класс-ларда катнашырга момкин.



